ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Законга кушымта нигезендә Ютазы муниципаль районы составына керә торган "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы", "Әбсәләм авыл җирлеге" һәм "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртергә.


**2 статья**

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, №1 (III өлеш); 2008, № 8 (III өлеш); 2014, № 11 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статус турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 6(22) – 1(74) | - Азнакай муниципаль районы |
| 1(74) – 23(75) | - Бөгелмә муниципаль районы |
| 23(75) – 20(23) | - Баулы муниципаль районы |
| 20(23) – 6(22) | - Башкортостан Республикасы |

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына
керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Урыссу шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Әбсәләм авыл җирлеге |
| 3 | Акбаш авыл җирлеге |
| 4 | Бәйрәкә авыл җирлеге |
| 5 | Бәйрәкәтамак авыл җирлеге |
| 6 | Димтамак авыл җирлеге |
| 7 | Кәрәкәшле авыл җирлеге |
| 8 | Иске Каразирек авыл җирлеге |
| 9 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 10 | Урыссу авыл җирлеге |
| 11 | Ютазы авыл җирлеге |

";

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

"Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Әбсәләм, Урыссу авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы белән чиктәш.

"Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Урыссу авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Урыссу һәм Әбсәләм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Урыссу авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып 250 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 250 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м һәм, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның

көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м уза, шуннан соң 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 450 м бара, шуннан соң Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 10 м уза, шуннан соң Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньяк-көнбатышка таба 550 м, көньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк-көнчыгышка таба 950 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 400 м, көньяк-көнбатышка таба 850 м, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, дамбаны кисеп үтеп, көньякка таба 550 м, көньяк-көнбатышка таба 300 м, көньяк-көнчыгышка таба 400 м "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Урыссу авыл җирлеге һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 400 м көньяк-көнчыгышта Ык елгасы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Башкортостан Республикасы белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасының административ чиге буйлап "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Әбсәләм авыл җирлеге һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 950 м көньякта Ык елгасы акваториясендә урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Әбсәләм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,7 км, көньяк-көнбатышка таба 300 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 4 нче кушымтаның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әбсәләм авыл җирлеге чиге Урыссу авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әбсәләм, Урыссу авыл җирлекләре һәм "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Иске Урыссу авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м Ютазы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 3,8 км Әбсәләм, Урыссу һәм Димтамак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яссытугай авылыннан 1,8 км көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Әбсәләм авыл җирлеге чиге "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Әбсәләм авыл җирлеге, "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге һәм Башкортостан Республикасы

чикләре тоташкан урында Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 950 м көньякта Ык елгасы акваториясендә урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,7 км, көньяк-көнбатышка таба 300 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 12 нче кушымтаның дүртенче – алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Урыссу авыл җирлеге чиге Башкортостан Республикасы белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Урыссу авыл җирлеге, "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 400 м көньяк-көнчыгышта Ык елгасы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урыссу авыл җирлеге чиге Әбсәләм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урыссу, Әбсәләм авыл җирлекләре һәм "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Иске Урыссу авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м Ютазы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 3,8 км Урыссу, Әбсәләм һәм Димтамак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яссытугай авылыннан 1,8 км көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урыссу авыл җирлеге чиге "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып 250 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 250 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м һәм, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м уза, шуннан соң 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 450 м бара, шуннан соң Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 10 м уза, шуннан соң Югары Стәрле – Иске Каразирек – Урыссу автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньяк-көнбатышка таба 550 м, көньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк-көнчыгышка таба 950 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 400 м, көньяк-көнбатышка таба 850 м, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, дамбаны кисеп үтеп, көньякка таба 550 м, көньяк-көнбатышка таба 300 м, көньяк-көнчыгышка таба 400 м 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 11 гыйнвар
№ 4-ТРЗ

Муниципаль берәмлекләр
чикләренең үзгәрешләр
исәпкә алынган карта-схемасы

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Ютазы муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең һәм Урыссу авыл җирлегенең чиктәш чиге
- Б-В - "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең һәм Башкортостан Республикасының чиктәш чиге
- А-В - "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең һәм Әбсәләм авыл җирлегенең чиктәш чиге
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге территориясе
- Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге территориясе